Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Манзарас авыл җирлеге Советы

# КАРАР

19.12.2023 ел №38

Манзарас авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 ноябреннан 2 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Манзарас авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Манзарас авыл Советының 2018 елның 27 мартыннан 11 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 2 ноябрендәге 32 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 14 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 9 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 15 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы, 2023 елның 31 октябрендагы 29 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Манзарас авыл җирлеге башлыгына классны чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы
урынбасары В.М.Ахатов